Республика Татарстан
Совет Чукмарлинского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге
советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31 июль 2019 ел Чукмарлы авылы № 13

Чукмарлы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендә кабул ителгән " Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" гы 18 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында " 2019 елның 1 маендагы 87 – ФЗ номерлы Федераль закон», Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә , Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Чукмарлы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендә кабул ителгән " Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" гы 18 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә;

1) 4 бүлекнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4.1.Гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашында хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә алдагы этапларда катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Чукмарлы авыл җирлеге Советы рәисе: И.Х.Хадиуллин